Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге
Кызыл Яшьләр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

28 октябрь, 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Кызыл Яшьләр торак пунктында 2023 елның 28 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 75 (җитмеш биш).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 39 (кырык).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 37 (утыз җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 2 (ике).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2024 елда Күн авыл җирлеге Кызыл Яшьләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау»
**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Күн авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Баһауов